**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4654**
**09.09.2022**

Башкарма комитетның «2022 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондының торак урыныннан файдалану өчен түләү (наем өчен түләү), торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» 2022 елның 19 гыйнварындагы 162 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясының 3 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы Карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 36 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, 2022 елга Яр Чаллы шәһәре буенча домофоннарга техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау хезмәтләренә чик түләү күләмен (бәясен) билгеләү тәкъдимнәрен исәпләү буенча бәйсез экспертиза нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2022 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондының торак урыныннан файдалану өчен түләү (наем өчен түләү), торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» 2022 елның 19 гыйнварындагы 162 номерлы карары (Башкарма комитетның 2022 елның 6 маендагы 2345 номерлы карары редакциясендә) кушымтасына, 4.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| № т/б | Түләү исеме | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | 01.10.2022 елдан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 4. | Төзелеш корылмаларын һәм биналарның инженерлык системаларын ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү, шул исәптән: | | |
| 4.10. | - домофоннар | хезмәт күрсәтелгән очракта, фатирның гомуми мәйданы квадрат метрыннан | 0,55 |

2. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов